ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**15.08.2023** **Чистай шәһәре** **№ 491**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
2016 елның 22 апрелендәге
«Вазыйфаи затларга административ
хокук бозулар турында беркетмәләр
төзү вәкаләтләрен бирү хакында»
247 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2023 елның 21 июлендәге “Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында” Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында”гы 67-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 апрелендәге «Вазыйфаи затларга административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү вәкаләтләрен бирү хакында» 247 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 18.04.2018 №293, 17.02.2020 №78, 08.05.2020 №227, 09.12.2020 №645, 26.08.2022 №552, 19.11.2022 №741 карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар кодексының түбәндәге статьясында каралган административ хокук бозулар составлары исемлеген тулыландырып, үзгәрешләр кертергә:
«2.21. статья – режим (база әзерлеге дәрәҗәсе) кысаларында чараларны гамәлгә ашыруны күздә тотучы Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе О.В. Заглядовага йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов